СОВЕТ МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘНАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№ 1-48 — «14 » октября 2019 года

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советының 18.09.2019 елның 1-47 санлы “Референдум үткәрү инициативасы турында”гы карарын гамәлдән чыгару турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә, «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумының 2019 елның 25 сентябренең ПР-147-2 санлы «2020 елда үзарасалым программасын гамәлгә ашыру мәсьәләләре турында" гы карарына таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2019 нчы елның 18 нче сентябрендә кабул ителгән “Референдум үткәрү инициативасы турында”гы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советының 1-47 нче санлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Мубаракшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе: Х.Х.Мубаракшин